2023
ГОД НАЦИОНАЛЬНЫХ
КУЛЬТУР И ТРАДИЦИЙ
МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЛӘР
ҺӘМ ГОРЕФ-ГАДӘТЛӘР ЕЛЫ

15 нче февраль көнне, герой-шагыйрь Муса Җәлилнең туган көненә багышлап, 9 нчы урта мәктәптә “Җәлил укулары” шигырь бәйгесе булып узды. Әйе, һәр халыкның үлемсез шагыйрьләре, телдән-телгә күчә торган легендар батырлары була. Муса Җәлил-шундый каһарманнарның, язучыларның берсе. Аның тормышы фашистларның кулында фаҗига белән тәмамланса да,шигъри язмышы бәхетле. Ул-үлем аша үлемсезлеккә атлаган бөек шәхес. Еллар үткән саен Муса Җәлилнең кеше күңеленә үтеп керү осталыгы, рухи көче, тәэсирлеге, нәфислеге арта гына бара. Бу бәйрәмдә 7-9 нчы сыйныф укучысы арасыннан Шайгарданов Айнур Муса Җәлилнең “Ышанма” шигырен сөйләп, 5-6 нчы сыфныфлар арасыннан Шайхулов Динар “Ишек төбендә” шигыре белән, башлынгыч сыйныфлардан Абрамов Кирилл М.Җәлилнең “Карак песи ” шигырен башкарып 1 нче урынны яуладылар. “Афәрин, егетләр!” диясе генә кала!